**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы**
**Иске Ибрай авыл Советы**

423078 Иске Ибрай авылы
Кооператив урамы, 2 йорт
тел. (факс) 884344- 4-63-72

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Совет Староибрайкинского сельского поселения Аксубаевского муниципального района**

423078 с. Старое Ибрайкино
улица Кооперативная, д.2

**КАРАР**

№47 09 нчы сентябрь 2022 ел

Иске Ибрай авыл җирлеге Советының 2018 нче елнын 7 июлендэге 69 номерлы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатыннан Аксубай муниципаль районының Иске Ибрай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Иске Ибрай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Ибрай авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» гы 2018 нче елнын 7 июлендэге 69 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 10 статьяны 10.8 пунктына тубэндэге эчтэлектэ өстәргә.: Җирлекнең генераль планы проекты һәм җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча ачык тыңлаулар, территорияне комплексы үстерү турында Карар кабул ителүгә бәйле рәвештә, авыл җирлегенең һәр торак пунктында үткәрелә;

1.2. 7 нче статьянын 7.2 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә. Гомуми тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләгән органга, тикшерелә торган мәсьәләләргә кагылышлы үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр халык алдында тыңлаулар беркетмәсенә кертү өчен тапшырырга хокуклы:

1) җыелыш яки халык алдында тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында язма яки телдән;

2) гавами тыңлауларны оештыручы адресына язмача яки электрон документ рәвешендә;

3) җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабында (журналда) язу аша.

1.3. 7.3 пунктыннан. «гавами тыңлаулар җирлек территориясендә үткәрелә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы рәсмисайтында: http:// Aksubayevo.tatarstan.ru.
3.Бу карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Аксубай муниципаль районы,
Иске Ибрай авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе М.Г.Минигулов